СОВЕТ ЯМБУЛАТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯМБУЛАТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

07.11.2023 с.Ямбулатово № 38 – 201

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Крестниково торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлеге Уставы статьясына ярашлы рәвештә, Крестниково торак пунктының бер өлеше халкы төркеменең инициативасын карап чыгып,

Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Крестниково торак пункты территориясенең бер өлешендә 2023 елның 19 ноябренә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар арасында халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: “Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Ямбулат авыл җирлегенең Крестниково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- Крестниково авылының Мәктәп урамындагы юлны вак ташлау өчен вак таш сатып алу һәм китерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Крестниково авылы, Мәктәп урамы, 6 йорт адресы буенча 12.00 сәгатьтә гражданнар җыенын уздырырга.
4. Ямбулат авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы урынбасары М.Н.Ахметзянов